**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

11.11.2025　　　　　　　　　　№ 1273

Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт башкарма хакимияте органнары тарафыннан күрсәтелүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында тәртипне раслау хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга(кушымта).

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июлендәге 725 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы сайтында (http://www.nurlat.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы　　　　　　　　　　Р.Г. Гиниятуллин